ГЛАВА БОЛЬШЕМЕМИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Молодежная, д.19, с. Большие Меми, 422588

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ОЛЫ МЕМИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшләр ур., 19 нче йорт, Олы Меми авылы, 422588

Тел.: (84379) 36-0-32, факс: (84379) 36-0-32.

10.11.2022 № 1

КАРАР

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Олы Меми авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, «2022 елның 10 ноябрендә Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Олы Меми авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы" мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

- «Олы Меми авылында зиратны, Бөек Ватан сугышы һәйкәле коймасын өлешчә тотып алу»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 204 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 125 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 125 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1 Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлегендә халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2 «Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Олы Меми авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесенең карары белән билгеләнгән ташламалы категориядәге гражданнардан тыш, һәр балигъ булган кешедән Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге Олы Меми авылында 2023 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы - «Олы Меми

авылында зиратны, Бөек Ватан сугышы һәйкәле коймасын өлешчә тотып алу» дигән карарны танырга.

3. Югары Ослан муниципаль районы Олы Меми авыл җирлеге Олы Меми авыл гражданнарның җыены нәтиҗәләрен Олы Меми авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына җибәрү өчен Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Олы Меми авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: Г.А. Фомина